# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«15» 09 2026 ел Яр Чаллы ш. №3065

2026 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик күләмнәрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик күләмнәрен билгеләү методикасы, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берләшмәсе» коммерциясез партнерлыгының 2026 елның 9 февралендәге 39 номерлы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» бәяләмәсе, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2026 елның 19 июнендәге 388/пр номерлы боерыгы нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күләмнәрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чиге:

- ялгыз яшәүче кеше өчен - 1 530 000 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен - 3 060 000 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен - 4 590 000 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен - 6 120 000 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен - 7 650 000 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен - 9 180 000 сум;
- җиде кешедән торган гаилә өчен - 10 710 000 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен - 12 240 000 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

- ялгыз яшәүче граждан өчен - 42846 сум 00 тиен;
- ике кешедән торган гаилә өчен - 42846 сум 00 тиен;

- өч һәм аннан артык кешедән торган гаилә өчен – 42846 сум 00 тиен.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарда күрсәтелгән максималь чик күрсәткечләрне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алганда кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның ___ 15.09. ___ 3065 номерлы карарына кушымта

**2026 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләмен билгеләү методикасы**

1. Муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алу өчен базар бәясенең хисап күрсәткече (алга таба - хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ, биредә

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар бәясенең хисап күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешенә туры килә торган торак урыны мәйданының бер квадрат метрының Татарстан Республикасында торак урыны алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен башкарма хакимиятнең тиешле федераль органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның уртача базар бәясеннән артмый торган уртача хисап бәясе.

«Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берләшмәсе» коммерциясез партнерлыгының 2026 елның 9 февралендәге 39 номерлы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» хатына, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2026 елның 19 июнендәге 388/пр номерлы боерыгына таянып, 2026 елга Тукай муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метрының бәяләүченең уртача медиана күрсәткечләреннән исәпләнгән уртача арифметик базар бәясен 85000 сум итеп билгеләргә мөмкин.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 85 000 х 18 = 1 530 000 сум 00 тиен

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 85 000 х (18х2) = 3 060 000 сум 00 тиен

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ =85 000 х (18 х 3) = 4 590 000 сум 00 тиен

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 85 000 х (18 х 4) = 6 120 000 сум 00 тиен

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 85 000 х (18 х 5) = 7 650 000 сум 00 тиен

е) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 85 000 х (18 х 6) = 9 180 000 сум 00 тиен

ж) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 85 000 х (18 х 7) = 10 710 000 сум 00 тиен

з) сигез кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 85 000 х (18 х 8) = 12 240 000 сум 00 тиен

2. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләменең чик күрсәткече:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) $^{-КП}$ ) / (0,3 х РС), биредә

ПД гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар бәясенең хисап күрсәткече;

ПС - ай өчен кредит буенча процент ставкасы (унлы вакланма). Коммерцияле кредит оешмаларының ачык чыганакларыннан алынган мәгълүмат буенча кредит буенча процент ставкасы үзгәреп тора, ташламалы ипотека буенча ставка 6% тан башлап 19% базар ставкасына кадәр. Уртача ставка - елына 12 %, ягъни 12/12/100 аена = 0,01 бер айга;

КП - бөтенкредит срогына кредит буенча түләүләрнең гомуми саны ( айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы.

## Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күләме хисабы

1 таб.

| НП - торак урыны нормасы (кв. м) | СЖ -торак урыны сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ Х НП) (сум) | РС- гаиләә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - 1 кв. м торак бинаның базар бәясе (сум) | ПС - айга кредит буенча процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы һәм фатир бәясенең чагыштырмасы | Кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы. | Керемнең чик күләме (сум) (кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | |
| | | | 85 000 | 12/12/100= 0,01 | 180 | 0,7 | 0,3 | |
| 18 | 1 530 000 | 1 | 85000 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,3 | 42 846,00 |
| 36 | 3 060 000 | 2 | 85000 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,6 | 42 846,00 |
| 54 | 4 590 000 | 3 | 85000 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,9 | 42 846,00 |
| 72 | 6 120 000 | 4 | 85000 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,2 | 42 846,00 |
| 90 | 7 650 000 | 5 | 85000 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,5 | 42 846,00 |
| 108 | 9 180 000 | 6 | 85000 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,8 | 42 846,00 |
| 126 | 10 710 000 | 7 | 85000 | 0,01 | 180 | 0,7 | 2,1 | 42 846,00 |
| 144 | 12 240 000 | 8 | 85000 | 0,01 | 180 | 0,7 | 2,4 | 42 846,00 |

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күләме хисабы

1. Ялгыз яшәүче кеше өчен:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,3 х РС) = 0,7 х 1 530 000 х 0,01 / (1 - 1/1,01$^{180}$) / (0,3 х 1) = 10 710/(1-0,16678)/0,30= 10 710/0,8332166/0,30= 42 846,00

2. Ике кешелек гаиләгә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,3 х РС) = 0,7 х 3 060 000 х 0,01 / (1 - 1/1,01$^{180}$)/(0,3 х 2) = 21 420 /(1-0,16678)/0,60= 21420/0,8332166/0,60 = 42 846,00

3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)-кп) / (0,3 х РС) = 0,7 х 4 590 000 х0,01 / (1 - 1/1,01180) / (0,3 х 3) = 32130/(1-0,16678)/0,90 = 32130/0,8332166/0,90 = 42 846,00